Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенә кергән Яңа Мокшино, Яңа Баланда авылларында халык җыены нәтиҗәләре турындагы

КАРАР

2019 елның 19 ноябре № 3

06.10.2003 елда кабул ителгән № 131нче номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 28.07.2004 ел, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы 2019 елның 5 ноябрендәге 105 номерлы карары белән 2019 елның 19 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Мокшино, Яңа Баланда авылларында узган, "Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм студентлардан тыш, 2020 елда бер тапкыр бирелә торган үзара салым акчаларын 500 сум итеп тулүәгә килешәсезме?» дигән сорау куелган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены протоколы төзелде. Җыеп алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелә:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген башкару:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге урамнарны кышкы тәртиптә тоту;

- Ленин урамы, Яңа Баланда авылы, Киров, Гагарин урамы урамнарын ремонтлау (грунт күтәрү, ком һәм вак таш салу);

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Яңа Мокшино авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- Яңа Баланда авылындагы зират каравылы өчен төзелеш материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛЫП КАЛДЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә 157 граждан, җыенда катнашучылар саны 82 кеше.
Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
«Риза» позициясе өчен 82 граждан тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
«Тыелып тордылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Мокшино, Яңа Баланда авылларында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен чын дип игълан итәргә.

"Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм студентлардан тыш, 2020 елда бер тапкыр бирелә торган үзара салым акчаларын 500 сум итеп түләүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча жыеп алынган акчаны

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген башкаруга:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге урамнарны кышкы тәртиптә тотуга;

- Ленин урамы, Яңа Баланда авылы, Киров, Гагарин урамы урамнарын ремонтлауга (грунт күтәрү, ком һәм вак таш салу);

2.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыруга:

- Яңа Мокшино авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алуга;

3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;

- Яңа Баланда авылы зират каравылы өчен төзелеш материаллары сатып алуга сарыф итәргә дигән карарны кабул итәргә.

4. Әлеге карарны Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының http://aksubaevo.tatar.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru/рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы башлыгы Н. В. Айдова